ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Луговнина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2017 елның 12 июле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.П. Луговнина шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.П. Луговнина «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 2 статьясындагы 2 пункты белән үзенең

конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган пункт белән пенсионерларга, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә, аз керемле гражданнарга, дарулар белән түләүсез тәэмин ителүгә хокуклы гражданнарга адреслы социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — пенсионер һәм аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмә буенча транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләнгән. Хезмәт эшчәнлеген туктату сәбәпле ул транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү күләмен яңадан карау турындагы гариза белән Дәүләт учреждениесе — Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе районындагы идарәсенә, Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районы буенча бүлегенә һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать иткән, ләкин аңа яңадан исәпләүдән баш тартылган.

Гражданка Г.П. Луговнина үзенең конституциячел хокукларының бозылуын шунда күрә: дәгъвалана торган норма анда санап чыгылган гражданнар категорияләрен, шул исәптән пенсионерларны адреслы социаль ярдәм күрсәтү чаралары турыдан-туры 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән гражданнарның башка категорияләре

белән тигез булмаган хәлгә куя. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, социаль ярдәм күрсәтү чараларының гражданнарның бер категорияләренә Татарстан Республикасы законы белән, ә башкаларына — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә бирелүендәге шундый аермалык тигезлек конституциячел принцибына туры килми һәм аның конституциячел хокукларын боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.П. Луговнина Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 30, 32, 38 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда (2013 елның 21 декабрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Әлеге статьяда каралган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла, шулай ук федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен

нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категорияләрен, шулай ук аларны күрсәтүнең конкрет күләмнәрен һәм рәвешләрен билгеләгән.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы дәгъвалана торган 2 пункты белән каралган билгеләнеше тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган гражданнарның аерым категорияләренең матди уңайлыкларына ярдәм итү булган хокукый җайга салу максатчан төсмергә ия һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү — Татарстан Республикасының хокукы, ә бурычы түгел. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата. Димәк, республика закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм җирле үзидарә органнарына дәгъвалана торган пунктта саналган гражданнар категорияләре мөнәсәбәтендә, шул исәптән Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып, социаль ярдәм күрсәтү чараларын да, аларны бирү тәртибен дә билгеләү буенча вәкаләтләрне тапшырырга хокуклы булган.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килеп тора, ул берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә

бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентацияләүне сайлап алганда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Моннан тыш, карала торган хокукый җайга салу, мөрәҗәгать итүче дәлилләренә каршы, тигезлек конституциячел принцибыннан тайпылуга китерми, чөнки, Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләгәнчә, бер категориядәге хокук субъектларына караган затлар өчен бертөрле хокуклар һәм бурычлар гарантияләп, әлеге принцип төрле категориядәге затлар өчен дифференциацияләнгән режим билгеләү мөмкинлегенә юл куя, әгәр андый дифференциация объектив шартларга бәйле булса һәм ирекле, дискриминацияли торган төсмергә ия булмаса (2001 елның 27 апрелендәге 7-П номерлы, 2004 елның 16 июлендәге 14-П номерлы һәм 2008 елның 13 мартындагы 5-П номерлы карарлар; 2005 елның 18 гыйнварындагы 55-О номерлы, 2005 елның 24 маендагы 177-О номерлы, 2009 елның 16 гыйнварындагы 147-О-О номерлы, 2012 елның 11 маендагы 743-О номерлы, 2012 елның 24 сентябрендәге 1583-О номерлы, 2013 елның 14 маендагы 692-О номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1925-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Шуның белән дәгъвалана торган норма үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданка Г.П. Луговнинаның да конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында»

Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү тәртибен үзгәртү турында ул куйган мәсьәләне хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә республика закон чыгаручысы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә карамый.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Луговнина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.П. Луговнинага,

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 32-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**